ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

15 декабрь 2020 ел №34

Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның район уртача нормасы турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясындагы 1 пункты, 40 статьясындагы 2 пункты нигезендә үз милкенә бирелә торган гражданнарның крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлегенең иң чик минималь күләмен билгеләү максатларында, авыл хуҗалыгы җирләрен районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре чикләрендә гражданнарның милкенә түләүсез тапшыру йомгаклары, «Гражданнар милкенә түләүсез тапшыру нормасын билгеләү тәртибе турында» 1992 елның 02 мартындагы 213 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы һәм җир реформасы буенча РСФСР Дәүләт комитетының 1992 елның 10 гыйнварындагы 3-15/51 номерлы крестьян (фермер) хуҗалыкларына ярдәм итү турында хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы, КАРАР ИТТЕ:

1. Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасын 2,79 гектар күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарәгә һәм авыл хуҗалыгына ярдәм итү буенча Нурлат муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин